**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г. Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2024 елның 09 декабрь** **102-РС номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы һәм «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.
3. Гамәлдәге законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше һәм «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 91 статьясындагы 2 өлеше нигезендә үз көченә керә дип билгеләргә..
4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек комиссиясенә йөкләргә..

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**

**Лаеш муниципаль районы Советының**
**2024 елның “—“ ___ ___номерлы карарына**
**кушымта**

**“Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1) 6 статьяның 1 пунктындагы 33 пунктчасында сүзләр өстәргә::

- ", шулай ук рекреацион максатларда су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен дә".

2) 41 статьяның 2 пунктын түбәндәге пункт белән тулыландырырга:

– – 6) аның чит ил агенты статусын алуы.

3) 45 статьяның 3 пунктындагы 10 пунктчасында сүзләр өстәргә:

- ", шулай ук рекреацион максатларда су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен".

4) 74 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, муниципаль берәмлек гамәлгә куйган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү булып түбәндәгеләр санала:

1) Тулы текстны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru (ЭЛ ММЧны теркәү турында 77 - 60244 номерлы таныклык - 2014 елның17 декабрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор)тарафыннан бирелгән яисә Лаеш муниципаль районының «Камская новь» газетасында ("Кама ягы")) Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең ТР буенча идарәсе 2013елның 16 маендагы рег. номеры Пи №ТУ16-01035,).

2) Лаеш муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб – адрес буенча урнаштыру: http://laishevo.tatarstan.ru.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен түбәндәге адреслар буенча урнашкан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары эшли: Лаеш районы, Лаеш шәһәре, Беренче Май урамы, 39 йорт (Лаеш муниципаль районы Советы бинасы).

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларга кул куелган көннән алып 10 көн эчендә халыкка җиткерелә.

5. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза салынган көннән үз көченә керә.

6. Муниципаль хокукый актлар, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр халыкка җиткерелә (рәсми басылып чыгудан тыш) торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле сайтларның доменнарын һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турында белешмәләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге гомуми игътибарга муниципаль берәмлек башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән җиткерелә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**